БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
19 август 2021 ел

**КАРАР**
№ 68

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында инициативалы проектларны карау, тәкъдим итү, кертү, фикер алышу Тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында инициативалы проектларны карау, тәкъдим итү, кертү, фикер алышу Тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча халыкка хәбәр итәргә: http://baltasi.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин

Балтач район Советының
2021елның 19 августындагы
68 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында инициатив проектларны тәкъдим итү, карауга кертү, алар буенча фикер алышу һәм карау Тәртибе**

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

### 1. Әлеге Тәртипне җайга салу предметы

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Конституциясе. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә инициатив проектларны тәкъдим итү, карауга кертүгә, алар буенча фикер алышу, карау, шулай ук аларны конкурс нигезендә сайлап алуга бәйле барлыкка килгән мөнәсәбәтләрне җайга сала.

1.2. Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән финанс ярдәме алу өчен күрсәтелә торган инициатив проектларны тәкъдим итү, карауга кертүгә, алар буенча фикер алышу, карау һәм сайлап алу белән бәйле мөнәсәбәтләргә, Татарстан Республикасы законы һәм (яисә) башка норматив хокукый акты һәм алар нигезендә кабул ителгән Балтач район Советы карарлары белән башкасы каралмаган булса, әлеге Тәртипнең нигезләмәләре кулланылмый.

### 2. Инициатив проектлар

2.1. Инициатив проект дигәндә әлеге Тәртиптә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне яисә җирле үзидарә органнарына хәл итү хокукы бирелгән башка мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы (алга таба - Муниципаль берәмлек) яисә аның бер өлешендә яшәүчеләрнең алар өчен өстенлекле әһәмияткә ия чараларны гамәлгә ашыру турындагы тәкъдиме аңлашыла.

2.2. Инициатив проектта түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) муниципаль берәмлек яисә аның бер өлешенең халкы өчен өстенлекле әһәмияткә ия проблеманы тасвирлау;

2) әлеге проблеманы хәл итү буенча тәкъдимнәрне нигезләү;

3) инициатив проектны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәсен (көтелгән нәтиҗәләрен) тасвирлау;

4) инициатив проектны гамәлгә ашыруга кирәкле чыгымнарны алдан исәпләү;

5) инициатив проектны гамәлгә ашыруның планлаштырыла торган вакытлары;

6) әлеге проектны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның планлаштырыла торган (мөмкин булган) финанс, мөлкәти һәм (яисә) хезмәти катнашуы турында белешмәләр;

7) инициатив түләүләрнең планлаштырылган күләменнән тыш, әлеге акчаларны инициатив проектны гамәлгә ашыруга куллану күздә тотылган очракта, муниципаль берәмлекнең бюджет акчалары күләмен күрсәтү;

8) аның чикләрендә әлеге Тәртипнең 3 статьясы нигезендә инициатив проект гамәлгә ашырылачак муниципаль берәмлек территориясен яисә өлешен күрсәтү.

2.3. Инициатив проект әлеге статьяның 2 өлешендә каралган белешмәләр булган, инициатор карары буенча график һәм (яки) таблица материаллары беркетеп бирү мөмкинлеге булган проект тасвирламасын үз эченә ала.

### 3. Халык мәнфәгатьләрендә инициатив проектлар гамәлгә ашырыла ала торган территорияне билгеләү

3.1. Инициатив проектлар тулаем алганда муниципаль берәмлек халкы мәнфәгатьләрендә, шулай ук түбәндәге территорияләрдәге халык мәнфәгатьләрендә гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) күпфатирлы йортның подъезды;

2) күпфатирлы йорт;

3) күп фатирлы йортлар һәм (яки) торак йортлар төркеме (шул исәптән урам, квартал яки планлаштыру структурасының башка элементы);

4) торак пункт;

5) торак пунктлар төркеме;

6) авыл җирлеге;

7) җирлекләр төркеме.

3.2. Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне (җирле үзидарә органнарына бирелгән башка мәсьәләләрне) хәл итү һәм (яисә) аерым муниципаль программалар чараларын үтәү буенча инициатив проектларны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән (шул исәптән муниципаль программаны раслау турындагы карар белән) Муниципаль берәмлек территориясен өлешләргә (округка) бүлү каралырга мөмкин. Әлеге очракта, инициатив проектлар Муниципаль берәмлек территориясенең (округының) тиешле өлеше чикләрендә күрсәтелә, тикшерелә һәм гамәлгә ашырыла.

## 2 бүлек. Инициатив проектларны тәкъдим итү һәм алар буенча фикер алышу

### 4. Проектның инициаторлары

4.1.Инициатив проектны карауга кертү инициативасына түбәндәгеләр хокуклы:

1) муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче кимендә ун уналты яшькә җиткән гражданнан торган инициатив төркем (алга таба - инициатив төркем);

2) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары;

3) авыл торак пункты старостасы.

4.2. Әлеге статьяның 4.1 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән затлар (алга таба - проект инициаторлары):

- инициатив проект әзерлиләр;
- инициатив проект буенча фикер алышуны оештыралар яисә әлеге бүлек нигезләмәләре нигезендә инициатив проектны хуплау мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерләрен ачыклауны тәэмин итәләр;
- инициатив проектны муниципаль берәмлекнең башкарма комитетына карауга кертәләр;
- инициатив проектны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуда катнашалар;
- әлеге Тәртиптә һәм муниципаль берәмлекнең аның нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актларында билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашыралар һәм вазыйфаларны башкаралар.

4.3. Инициатив төркем төзү һәм аның тарафыннан әлеге статьяның 4.2 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү беркетмә белән рәсмиләштерелә.

4.4. Әлеге статьяның 4.2 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча карарлар территориаль иҗтимагый үзидарә уставы нигезендә территориаль иҗтимагый үзидарә органнары булып торучы проект инициаторлары тарафыннан кабул ителә.

4.5. Әлеге статьяның 4.2 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча карарлар иҗтимагый берләшмәләр булып торучы проектның инициаторлары тарафыннан аларның гамәлгә кую документлары нигезендә кабул ителә.

## 5. Инициатив проектны хуплау мәсьәләсе буенча гражданнар фикерен ачыклау

5.1. Инициатив проект алар мәнфәгатьләрендә инициатив проектны гамәлгә ашыру күздә тотыла торган муниципаль берәмлек халкы яисә аның өлеше тарафыннан хупланырга тиеш.

5.2. Проект инициаторы инициатив проектны хуплау мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерләрен ачыклауны түбәндәге формаларда оештыра:

1) инициатив проектны гражданнар җыенында карау;

2) инициатив проектны гражданнар җыелышында яисә конференциясендә карау, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында яисә конференциясендә;

3) гражданнарны сораштыру үткәрү;

4) инициатив проектны хуплаган гражданнардан имзалар җыю.

5.3. Проектның инициаторы инициатив проектны хуплау мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерен ачыклауның формасыннан (берничә формасыннан) файдалану турында карар кабул итәргә хокуклы.

## 6. Инициатив проектларны тәкъдим итү мәсьәләләре буенча гражданнар җыены

6.1. Инициатив проектны тәкъдим итү мәсьәләләре буенча гражданнар җыены (алга таба - җыен) проект инициаторы карары белән билгеләнә һәм үткәрелә.

6.2. Җыен үткәрү турында проект инициаторының мөрәҗәгатендә күрсәтелә:

- проект инициаторы турында белешмәләр (инициатив төркем әгъзаларының фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, аларның яшәү яки тору урыны турында белешмәләр, авыл торак пункты старостасының исеме, фамилиясе, атасының исеме, чара проектының башка инициаторы исеме һәм аның урнашу урыны);

- инициатив проект турында мәгълүмат;

- инициатив проектны тәкъдим итү мәсьәләләре буенча муниципаль берәмлек Башкарма комитеты белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашырырга вәкаләтле затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре,телефон номерлары;

- җыенның датасы, вакыты һәм урыны турында тәкъдимнәр.

6.3. Җыен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы һәм тиешле нигезләмә белән билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

6.4. Җыен үткәрү турында берничә үтенечнамә килгән очракта, бер җыенда берничә инициатив проектны карау мөмкин.

## 7. Инициатив проектларны тәкъдим итү мәсьәләләре буенча гражданнар җыены

7.1. Инициатив проектны тәкъдим итү мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышы (алга таба - җыелыш) проект инициаторы карары белән билгеләнә һәм үткәрелә.

7.2. Җыелыш аның халкы мәнфәгатьләрендә инициатив проектны гамәлгә ашыру планлаштырыла торган муниципаль берәмлек территориясе өлешендә үткәрелә. Инициатив проектны гамәлгә ашыру тулаем алганда муниципаль берәмлек халкы мәнфәгатьләрендә планлаштырыла икән, муниципаль берәмлек территориясенең төрле өлешләрендә берничә җыелыш уздырылырга мөмкин.

7.3. Җыелышта уналты яшькә җиткән әлеге территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы.

7.4. Җыелыш түбәндәгечә үткәрелә:

1) турыдан-туры карау формасында - көн тәртибе мәсьәләләре буенча фикер алышу һәм тавыш бирүгә куелган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү өчен халыкның берләшеп катнашуы формасында;

2) турыдан-туры-читтән торып карау формасында - көн тәртибе мәсьәләләре буенча фикер алышу һәм тавыш бирүгә куелган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү мөмкинлеген, шулай ук җыелыш үткәрү турында хәбәрдә күрсәтелгән урынга яки адрес буенча билгеләнгән вакытка карарларны тапшыру яисә "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып тавыш бирү (алга таба - махсуслаштырылган сайт) мөмкинлеген күздә тоткан формада.

7.4. Бер җыелышта берничә инициатив проект каралырга мөмкин. Бу очракта җыелышны оештыру һәм уздыру буенча хокук һәм бурычлар проектлар инициаторлары тарафыннан бергә гамәлгә ашырыла.

7.5. Җыелыш үткәрү, документлар әзерләү һәм тарату чыгымнарын проект инициаторы күтәрә.

7.6. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты проект инициаторына җыелыш үткәрүдә ярдәм күрсәтә, шул исәптән аны үткәрү өчен түләүсез нигездә бина бирә.

7.7. Җыелыш анын халкы мәнфәгатьләрендә инициатив проектны гамәлгә ашыру планлаштырыла торган муниципаль берәмлек территориясе өлешендәге яшәүче халкының 50% тан артыгы катнашса, җыелыш тулы хокуклы дип санала.

## 8. Җыенны үткәрүгә әзерлек

8.1. Җыелышны уздыру турында проект инициаторының карарында түбәндәгеләр күрсәтелә:

- җыелыш анын буенча фикер алышу үткәрелә торган инициатив проект;

- җыелышны уздыру формасы (турыдан-туры карау яисә турыдан-туры-читтән торып карау);

- җыелышның көн тәртибе, җыелыш читтән торып уздырылган очракта - халыкның тавыш бирүен уздыру планлаштырыла торган мәсьәләләр;

- җыелыш уздыру датасы, вакыты, урыны, ә турыдан-туры-читтән торып карау уздырылган очракта - шулай ук тавыш бирүгә куелган мәсьәләләр буенча халыкның карарларын кабул итү тәмамлану датасы һәм мондый карарлар тапшырылырга тиешле урын яисә адрес, яисә тавыш бирүгә куелган мәсьәләләр буенча тавыш бирү өчен махсуслаштырылган сайттан файдалану турында карар;

- турыдан-туры карау формада үткәрелә торган җыелышта катнашучыларның яисә турыдан-туры-читтән торып карау үткәргән очракта, көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашучылар саны;

- җыелыш үткәрелә торган территориядә аны уздыру турында халыкка мәгълүмат бирү ысуллары.

8.2. Проект инициаторы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына җыелыш үткәрү турында аны уздыру көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча язма хәбәрнамә җибәрә.

8.3. Җыелышны уздыру турында хәбәрнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) проект инициаторы турында белешмәләр (инициатив төркем әгъзаларының фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, аларның яшәү яисә булу урыны турында белешмәләр, авыл торак пункты старостасының фамилиясе, исеме, атасының исеме, чараның башка инициаторы исеме һәм анын урнашкан урыны);

2) әлеге статьяның 8.1 пунктында каралган белешмәләр;

3) җыелышны оештыру һәм уздыру буенча күрсәтмә бирү функцияләрен үтәргә тиешле проект инициаторлары вәкаләт биргән затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, телефон номерлары.

4) җыелыш уздыруга ярдәм итү турында, шул исәптән җыелышны үткәрү (җыелышны турыдан-туры-читтән торып карау формасында үткәрү очрагында турыдан-туры карау формасындада фикер алышу) өчен бина бирү һәм (яки) тавышка куелган мәсьәләләр буенча халыкның тавыш бирүе өчен махсус сайттан файдалану турында үтенеч.

8.4. Җыелышны уздыру турында хәбәрнамәгә проект инициаторы һәм аны оештыру һәм уздыру буенча күрсәтмә бирү функцияләрен үтәргә вәкаләтле затлар тарафыннан имза куела. Инициатив төркем исеменнән җыелыш үткәрү турында хәбәрнамәгә аны оештыру һәм уздыру буенча күрсәтмә функциясен үтәргә вәкаләтле затлар имза куя.

8.5. Җыелышны уздыру өчен урын бирү турында үтенеч булган очракта, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты хәбәр кергән көннән алып өч көн эчендә бина бирү мөмкинлеге турында проект инициаторына хәбәр итә яисә җыелышны уздыру урынын һәм (яисә) датасын һәм вакытын үзгәртергә тәкъдим итә. Проектның инициаторы күрсәтелгән тәкъдимне алган көннән алып өч көн эчендә җыелышны (җыелыш читтән торып уздырылган очракта, тәкъдимнәр буенча фикер алышуны) уздыру урынын һәм (яисә) датасын һәм вакытын үзгәртүгә ризалыгы яисә килешмәве турында хәбәр итәргә тиеш.

8.6. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Балтач муниципаль районының рәсми сайтында җыелышны уздыру турында, шул исәптән инициатив проект белән танышу тәртибе турында белешмәләрне түбәндәгечә урнаштыра:

- җыелыш үткәрү турында хәбәрнамә кергән көннән соң өч көн эчендә;

- урынын һәм (яисә) җыелышны уздыру датасын һәм вакытын үзгәртү турындагы тәкъдим белән проект инициаторы ризалыгын алганнан соң ике көннән дә соңга калмыйча (җыелыш турыдан-туры-читтән торып карау формасында уздырылган очракта, турыдан-туры карау формасында фикер алышу).

8.7. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты проект инициаторына җыелыш үткәрүдә ярдәм итү максатларында вәкаләтле вәкил билгели. Вәкаләтле вәкилне билгеләү турында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты проект инициаторына алдан ук хәбәр итә.

## 9. Җыен турыдан-туры карау формасында уздыру тәртибе

9.1. Җыелыш башланганчы проект инициаторы җыелышта катнашкан гражданнарны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты раслаган форма буенча исемлек төзеп, теркәүне тәэмин итә. Җыелышта катнашкан гражданнар исемлеге җыелыш беркетмәсенең аерылгысыз өлеше булып тора.

9.2. Җыелышның көн тәртибенә караган мәсьәләләр буенча тавыш бирү тәртибе җыелышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән раслана. Көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча карарлар җыелышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

9.3. Җыелыш проект инициаторы вәкиле тарафыннан ачыла. Җыелышны алып бару өчен рәис һәм секретарь сайлана.

9.4. Рәис җыелышны алып бара, көн тәртибендәге мәсьәләләрне игълан итә, катнашучыларга чыгыш ясау өчен сүз бирә, җыелышта кабул ителгән карарларны формалаштыра, аларны тавыш бирүгә куя, тавыш бирү нәтиҗәләрен игълан итә.

9.5. Секретарь җыелыш беркетмәсен алып бара, ул беркетмәдә тавыш бирү нәтиҗәләрен күрсәтеп, җыелыш кабул иткән барлык карарлар чагылдырыла. Җыелыш беркетмәсенә секретарь һәм җыелыш рәисе имза куя.

9.6. Җыелыш беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- җыелышны уздыру урыны һәм вакыты;
- җыелышта катнашкан гражданнар саны;
- яшәү урынын күрсәтеп, җыелыш рәисе һәм секретаре турында белешмәләр;
- җыелышның көн тәртибе, чыгышларның эчтәлеге;
- көн тәртибенә кагылышлы кабул ителгән карарлар.

## 10. Җыелышны турыдан-туры-читтән торып карау формасында үткәрү тәртибе

10.1. Җыелыш турыдан-туры-читтән торып карау формасында үткәрелгән очракта, көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча турыдан-туры фикер алышу һәм тавышка куелган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү әлеге Тәртипнең 9 статьясында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

10.2. Турыдан-туры фикер алышуда катнашмаган затлар җыелышны үткәрү турында хәбәрдә күрсәтелгән урынга яки адрес буенча тавышка куелган мәсьәләләр буенча язма формада рәсмиләштерелгән карарны җибәрергә хокуклы.

10.3. Турыдан-туры-читтән торып карау формасында үткәрелә торган җыелышта катнашучылар булып, турыдан-туры фикер алышуда катнашкан затлар, шулай ук карарлар кабул итү тәмамланганчы алынган затлар санала.

10.4. Җыелыш махсус сайттан файдаланып, турыдын-туры-читтән торып карау формасында уздырылган очракта, җыелышны үткәрү турында һәм көн тәртибе мәсьәләләре буенча турыдан-туры фикер алышуда катнашмаган затларның тавыш бирүе турында хәбәр урнаштыру күрсәтелгән сайтта үткәрелә.

10.5. Җыелышның көн тәртибе мәсьәләләре буенча тавыш бирү махсус сайттан файдаланып, җыелыш үткәрелә торган территориядә яшәүчеләр тарафыннан шәхсән көн тәртибендәге һәр мәсьәлә буенча карарны "Риза", "Риза түгел" яки "Җавап бирүдән тыелам" формулировкалары белән чагылдырып күрсәтү юлы белән башкарыла. Махсус сайтны кулланып тавыш бирүдә катнашучылар булып тавыш бирү датасына һәм вакытына кадәр электрон формада тавыш биргән кешеләр санала. Халыкны идентификацияләү Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы хисап язмасын кулланып башкарыла. Тавыш бирү аның башлану датасыннан һәм вакытыннан тәмамлану датасына һәм вакытына кадәр туктаусыз үткәрелә.

10.6. Махсус сайтны кулланып тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмә рәвешендә формалаштырыла һәм сайтта мондый тавыш бирү тәмамланганнан соң бер көн эчендә урнаштырыла. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты расланган тавыш бирү беркетмәсен проект инициаторына аларны формалаштырганнан соң өч көн дәвамында җибәрә. Күрсәтелгән беркетмә җыелыш беркетмәсенең аерылгысыз өлеше булып тора.

10.7. Тавыш бирүне уздырганда җыелышта катнашучы һәр кешедән "Шәхси мәгълүматлар турында" Федераль законның 9 статьясында билгеләнгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелә торган шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы алынырга тиеш.

10.8. Тавыш бирү тәмамланганнан соң, сораштыру юлы белән яки махсус сайтны кулланып, секретарь җыелыш беркетмәсен әзерли, аңа җыелыш секретаре һәм рәисе имза куя.

10.9. Турыдан туры-читтән торып карау формасында уздырыла торган җыелыш беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- турыдан-туры фикер алышу урыны һәм вакыты;

- читтән торып тавыш бирү ысулы, аның башлану һәм тәмамлану датасы һәм вакыты;

- җыелышта катнашкан гражданнар саны;

- яшәү урыннарын күрсәтеп, җыелышның рәисе һәм секретаре турында белешмәләр;

- турыдан-туры фикер алышуларда җыелышның көн тәртибе, чыгышларның эчтәлеге;

- көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча кабул ителгән карарлар һәм алар буенча тавыш бирү нәтиҗәләре.

## 11. Инициатив проектларны тәкъдим итү мәсьәләләре буенча гражданнар конференциясе үткәрү

11.1. Инициатив проектны гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территориядә 16 яшькә җиткән яшәүчеләр саны 1000 кешедән артып киткән очракта, инициатив проектларны тәкъдим итү мәсьәләләре буенча гражданнар конференциясе (алга таба - конференция) уздырылырга мөмкин.

11.2. Конференция әлеге статьяда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, әлеге Тәртипнең 7 - 10 статьяларында билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

11.3. Әлеге Тәртипнең 8 статьясының 8.1 пунктында каралган нигезләмәләр белән беррәттән, конференция үткәрү турында проект инициаторы карарында түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

1) территориядә яшәүче 16 яшькә җиткән 100 кешегә 1 делегаттан ким булмаган делегатлар сайлау өчен вәкиллек нормасы;

2) делегатларны сайлау өчен җыелышлар уздыру вакытлары һәм тәртибе.

11.4. Делегатларны сайлау турында җыелыш беркетмәләре конференция беркетмәсенең аерылгысыз өлеше булып тора.

## 12. Инициатив проектларны хуплау йөзеннән гражданнар имзаларын җыю

12.1. Инициатив проектларны хуплау йөзеннән гражданнар имзаларын җыю (алга таба - имзалар җыю) проект инициаторы тарафыннан үткәрелә.

12.2. Инициатив проектларны хуплау йөзеннән җыелган имзалар саны, инициатив төркем әгъзаларының имзаларын да кертеп, кимендә егерме биш булырга тиеш.

12.3. Имзалар түбәндәге тәртиптә җыела:

1) имзалар формасы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан расланган имзалар кәгазенә кертү юлы белән җыела;

2) имзалар кәгазендә имзалар җыюны гамәлгә ашырыла торган инициатив проект күрсәтелә;

3) имзалар кәгазендә кешенең имзасы һәм аны кую датасы куела. Имза һәм аны кую датасын кеше үз кулы белән куя. Имзалар кәгазендә үз имзасын куйган кеше турында белешмәләр имзалар җыюны гамәлгә ашыручы зат тарафыннан имза кәгазенә кертелергә мөмкин. Күрсәтелгән белешмәләр бары тик кулъязма ысул белән генә кертелә, шул ук вакытта карандашлар куллану рөхсәт ителми;

4) кеше бер үк инициатив проектны хуплап бер генә тапкыр имза куярга хокуклы;

5) һәр имзалар кәгазе имзалар җыюны гамәлгә ашыручы проект инициаторының имзалары белән расланырга тиеш. Имзалар кәгазен раслаганда, имзалар җыюны башкарган проект инициаторы вәкиле үз кулы белән фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, туу датасын, яшәү урыны адресын күрсәтә, шулай ук имзасын куя һәм аны кую датасын күрсәтә;

6) имзалар җыйганда, имзалар кәгазенең алгы ягын һәм арткы ягын тутыру рөхсәт ителә. Шул ук вакытта арткы як имзаларның бердәм нумерациясе алгы якның дәвамы булып тора, ә раслау имзалары һәм имзалар җыюны гамәлгә ашыручы проект инициаторы вәкиле турында белешмәләр имзалар кәгазенең арткы ягына соңгы имзадан соң куела;

7) имзалар җыйганда һәр кешедән "Шәхси мәгълүматлар турында" Федераль законның 9 статьясында билгеләнгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелә торган шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы алынырга тиеш.

## 13. Әлеге инициатив проектны хуплау турында аларның фикерен ачыклау өчен гражданнарны сораштыру үткәрү

13.1. Әлеге инициатив проектны хуплау турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен гражданнарны сораштыру (алга таба - сораштыру) инициатив проектны гамәлгә ашыру планлаштырылган муниципаль берәмлектә яисә аның өлешендә яшәүчеләр инициативасы буенча түбәндәге очракларда башкарыла:

1) инициатив проект тулаем Муниципаль берәмлектәге халык мәнфәгатьләрендә гамәлгә ашырырга тәкъдим ителгән очракта;

2) инициатив проект Муниципаль берәмлекнең халык саны 1000 кешедән арткан бер өлешендәге халык мәнфәгатьләрендә гамәлгә ашырырга тәкъдим ителгән очракта.

13.2. Сораштыруны билгеләү өчен проект инициаторы Муниципаль берәмлек Советына гариза җибәрә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) аңа карата сораштыру уздыру тәкъдим ителә торган инициатив проект;

2) проект инициаторы тәкъдимнәре:

а) сораштыру үткәрү датасы һәм вакытлары турында;

б) сораштыру уздырганда тәкъдим ителә торган сорауны (сорауларны) формалаштыру турында;

в) сораштыру үткәрү методикасы турында;

г) сораштыруда катнашучы Муниципаль берәмлек халкының минималь саны турында;

3) проект инициаторы турында белешмәләр (инициатив төркем әгъзаларының фамилиясе, исемнәре, аталарының исемнәре, аларның яшәү яисә булу урыны турында белешмәләр, авыл торак пункты старостасының фамилиясе, исеме, атасының исеме, чараның башка инициаторы исеме һәм аның урнашкан урыны).

13.3. Әгәр проектның инициаторы инициатив төркем булса, гариза инициатив төркемнең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Әгәр проектның инициаторы әлеге Тәртипнең 4 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән башка затлар булса, гариза проект инициаторының вәкаләтле заты һәм инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган Муниципаль берәмлекнең яисә

аның өлешенең кимендә 10 кешесе тарафыннан имзалана. Бу очракта гаризада шулай ук гаризаны имзалаган затлар турында белешмәләр (фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, аларның яшәү урыны яки булу урыны турында белешмәләр) күрсәтелә.

13.4. Муниципаль берәмлек Советы гариза кергән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча аны карый һәм сораштыру билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә.

13.5. Сораштыруны билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып әлеге статьяда билгеләнгән сораштыру уздыру турындагы инициативаны тәкъдим итү тәртибен бозу тора, әгәр җибәрелгән хокук бозулар инициативаны күрсәтүдә катнашкан муниципаль берәмлек халкының ихтыяр белдерү нәтиҗәләрен дөрес итеп билгеләргә мөмкинлек бирмәсә.

13.6. Инициатив проектларны тәкъдим итү мәсьәләләре буенча гражданнардан сораштыру "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясындагы 4 өлеше нигезендә гражданнарны сораштыруны билгеләү һәм аны үткәрү тәртибен билгели торган норматив хокукый актта билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

13.7. Сораштыруда инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлектә яисә аның өлешендә 16 яшькә җиткән яшәүчеләр катнашырга хокуклы.

13.8. Башкарма комитет сораштыру нәтиҗәләре чыгарылганнан соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча аларны проект инициаторына белешмә өчен җиткерә.

## 3 бүлек. Инициатив проектларны карауга кертү һәм карау

### 14. Инициатив проектларны Балтач район башкарма комитетына карауга кертү

14.1. Инициатив проектны Балтач район башкарма комитетына керткәндә түбәндәгеләр тапшырыла:

1) проектның график һәм (яисә) таблица материаллары теркәлергә мөмкин булган басма чыганактагы һәм электрон формадагы тасвирламасы;

2) инициатив төркем төзү беркетмәсе яисә әлеге Нигезләмәнең 4 статьясындагы 4, 5 өлешләре нигезендә башка документлар, шулай ук инициатив проектны караганда һәм гамәлгә ашырганда инициатив төркем исеменнән эш итәргә вәкаләтле затларны билгеләү турында проект инициаторы карары;

3) гражданнар җыены, җыелышы яисә конференциясе беркетмәсе, гражданнарны сораштыру нәтиҗәләре һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең яисә аның бер өлешенең халкының инициатив проектка хуплавын раслый торган имзалар кәгазьләре.

14.2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән документлар инициатив проектны караганда һәм гамәлгә ашырганда Балтач район башкарма комитеты белән эш итәргә вәкаләтле зат тарафыннан турыдан-туры Балтач район башкарма комитетына тапшырыла яисә кыйммәте турында белешмә һәм җибәрелгән документлар исемлеге белән почта аша җибәрелә.

14.3. Проектны карауга кертү датасы булып Балтач район башкарма комитеты тарафыннан әлеге статьяның 14.1 пунктында күрсәтелгән документларны алу көне тора.

14.4. Әгәр документлар инициатив проектны караганда һәм гамәлгә ашырганда иницитор тарафыннан Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты белән эш итәргә вәкаләтләр бирелгән зат тарафыннан Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына турыдан-туры тапшырылса, күрсәтелгән затка, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан исемлеген һәм аларны алу датасын күрсәтеп, документларны кабул итү турында раслау кәгазе бирелә. Раслау кәгазе документларны алган көнне Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан бирелергә тиеш.

**15. Инициатив проектларны карау комиссиясе**[1]

15.1. Инициатив проектларны карау комиссиясе (алга таба - комиссия) инициатив проектларның социаль-икътисадый әһәмиятен объектив бәяләү һәм аларны конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру максатларында төзелә.

15.2. Комиссия 6 кешедән тора.

15.3. Комиссиянең персональ составы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары белән билгеләнә. Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан яртысы муниципаль берәмлек Советы тәкъдимнәре нигезендә билгеләнә. Комиссия составы комиссия кабул итә торган карарларга йогынты ясарга мөмкин булган мәнфәгатьләр конфликтлары барлыкка килү мөмкинлеген булдырмау өчен төзелә.

15.4. Комиссия комиссия рәисеннән, комиссия рәисе урынбасарыннан, комиссия секретареннан һәм аның эшендә шәхсән катнашучы комиссия әгъзаларыннан тора.

15.5. Комиссия рәисе:

- комиссия эшен оештыра, аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә;
- комиссиянең чираттагы утырышының көн тәртибе проектын формалаштыра;
- комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә;
- комиссия утырышларында рәислек итә.

15.6. Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, конкурс комиссиясе рәисе вакытлыча булмаган очракта, аның вазыйфаларын башкара.

15.7. Комиссия секретаре:

- комиссия эшчәнлеген мәгълүмат һәм документлар белән тәэмин итә, шул исәптән комиссия утырышына әзерлекне тәэмин итә;
- комиссия әгъзаларына, комиссия утырышына чакырылган проектлар инициаторларына һәм башка затларга комиссиянең чираттагы утырышын уздыру датасы, урыны һәм комиссиянең чираттагы утырышының көн тәртибе турында хәбәр итә;
- комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бара.

15.8. Комиссия әгъзасы:

- комиссия эшендә, шул исәптән комиссия утырышларында катнаша;
- комиссия эше мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр кертә;

- комиссия утырышларында карала торган документлар һәм материаллар белән таныша;

- комиссия утырышында катнашучыларга сораулар бирә;

- комиссия утырышларында тавыш бирә.

15.9. Комиссия эшенең төп формасы булып утырышлар тора.

15.10. Утырышта әгъзаларның яртысыннан ким булмаган өлеше катнашканда Комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала.

15.11. Проектның инициаторларына һәм аларның вәкилләренә комиссия тарафыннан инициатив проектларны караудa катнашу һәм алар буенча үз позицияләрен бәян итү мөмкинлеге тәэмин ителә. Проект инициаторлары инициатив проектны карау планлаштырыла торган комиссия утырышы турында аны үткәрү көненә кадәр биш көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

15.12. Проект буенча фикер алышу һәм комиссия тарафыннан карарлар кабул итү проект инициаторы һәм чакырылган башка затлар катнашыннан башка башкарыла.

15.13. Комиссия карары утырышта катнашучы комиссия әгъзалары саныннан гади күпчелек тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

15.14. Комиссия әгъзалары карарлар кабул итү турындагы мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия.

15.15. Комиссия кабул иткән карар белән килешмәгән очракта, комиссия әгъзасы үзенең аерым фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул комиссия утырышы беркетмәсенә беркетелергә тиеш.

15.16. Комиссия утырышы нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелә, ул комиссия утырышында рәислек итүче, комиссия секретаре һәм комиссия утырышында катнашкан комиссия әгъзалары тарафыннан комиссия утырышын үткәргән көннән алып өч эш көне эчендә имзалана.

15.17. Комиссия секретаре комиссия утырышы беркетмәсенә имза куелган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча аны муниципаль берәмлекнең башкарма комитетына җибәрә.

15.18. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне татарстан Республикасы балтач район башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

**16. Балтач район башкарма комитеты тарафыннан инициатив проектны карау тәртибе**

16.1. Инициатив проект Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан аны керткән көннән соң 30 көн эчендә карала.

16.2. Инициатив проектны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына кертү турындагы мәгълүмат Балтач район башкарма комитетына кертелгән көннән алып өч эш көне эчендә "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Балтач муниципаль районының рәсми сайтында басылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм үз эченә әлеге Тәртипнең 2 статьясының 2.2 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне, шулай ук проект инициаторлары турында белешмәләрне алырга тиеш. Бер үк вакытта гражданнарга аларны тәкъдим итү вакытын күрсәтеп, үзләренең инициатив

проект буенча кисәтүләрен һәм тәкъдимнәрен Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына тапшыру мөмкинлеге турында хәбәр ителә.

16.3. Инициатив проект буенча кисәтүләр һәм тәкъдимнәр кертү вакыты - җиде эш көне тәшкил итә. Муниципаль берәмлекнең 16 яшькә җиткән кешеләре үзләренең кисәтүләрен һәм тәкъдимнәрен җибәрергә хокуклы. Кисәтүләр һәм тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына кеше тарафыннан турыдан-туры тапшырыла яисә почта аша җибәрелә.

16.4. Инициатив проект буенча кисәтүләрне һәм тәкъдимнәрне гомумиләштерүне комиссия гамәлгә ашыра.

16.5. Инициатив проектны карау нәтиҗәләре буенча комиссия Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә әлеге статьяның 16.8 пунктында күрсәтелгән карарларның берсен кабул итәргә тәкъдим итә. Комиссия карарында шулай ук проектны эшләп бетерү буенча тәкъдимнәр булырга мөмкин.

16.6. Муниципаль берәмлекнең башкарма комитетына берничә инициатив проект кертелгән очракта, шул исәптән эчтәлеге буенча шундый ук өстенлекле проблемаларны тасвирлаганда, комиссия муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты җитәкчесенә конкурс нигезендә сайлап алуны оештыруны тәкъдим итә.

16.7. Конкурста сайлап алу әлеге Тәртипнең 17 статьясы нигезендә оештырыла. Конкурста сайлап алуны үткәрү турындагы хәбәр проектлар инициаторларына тиешле карар кабул ителгәннән соң өч көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

16.8. Комиссия киңәшен исәпкә алып яисә конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) инициатив проектны хупларга һәм аның өстендә эшләүне муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карар белән тиешле максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм (яисә) муниципаль берәмлек бюджеты (муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү) проектын төзү һәм карау тәртибе нигезендә дәвам итәргә;

2) инициатив проектны хуплаудан баш тартырга һәм инициатив проектны хуплаудан баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, аны проект инициаторларына кире кайтарырга.

16.9. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе түбәндәге очракларның берсендә инициатив проектны хуплаудан баш тарту турында карар кабул итә:

1) инициатив проектны карауга кертүнең һәм аны карауның билгеләнгән тәртибен үтәмәү;

2) инициатив проектның федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары таләпләренә, Татарстан Республикасы законнарына һәм башка норматив хокукый актларга, муниципаль берәмлек Уставына туры килмәве;

3) җирле үзидарә органнарының кирәкле вәкаләтләре һәм хокуклары булмаганлыктан, инициатив проектны гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмау;

4) инициатив проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләмендә чыганагы инициатив түләүләр булмаган муниципаль берәмлекнең бюджет акчалары булмау;

5) инициатив проектта тасвирланган проблеманы нәтиҗәлерәк хәл итү мөмкинлеге булу;

6) инициатив проектны конкурс буенча сайлап алуны узмаган дип тану.

16.10. Карар проектны карау нәтиҗәләре буенча карар кабул ителгән көннән соң өч көннән дә соңга калмыйча проект инициаторына җибәрелә.

16.11. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты әлеге статьяның 8 өлешендәге 5 пунктында каралган очракта, проект инициаторларына бергәләп инициатив проектны эшләп бетерергә тәкъдим итәргә, шулай ук аны үз компетенцияләре нигезендә башка муниципаль берәмлекнең яисә дәүләт органының җирле үзидарә органы каравына тәкъдим итәргә тиеш. Проектны эшләп бетерү өчен комиссия әгъзалары, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты вәкилләре, проект инициаторы вәкилләре арасыннан эшче төркем төзи, шулай ук проектны эшләп бетерү вакытын билгели. Эшләп бетерелгән инициатив проект комиссия тарафыннан әлеге Тәртипнең 15 статьясы һәм әлеге статья нигезендә карала.

## 17. Инициатив проектларны конкурс нигезендә сайлап алу

17.1. Конкурста сайлап алуны комиссия гамәлгә ашыра.

17.2. Конкурста сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:

1) инициатив проект аларны хәл итүгә юнәлдерелгән проблемаларны билгеләүдә һәм аны гамәлгә ашыруга юнәлтелгән проблеманы ачыклауда халыкның катнашу дәрәҗәсе;

2) инициатив проектны гамәлгә ашыруның социаль нәтиҗәлелеге.

17.3. Конкурста сайлап алу әлеге Тәртипнең 15 статьясы нигезендә үткәрелә торган комиссия утырышында гамәлгә ашырыла.

17.4. Комиссия инициатив проектларны конкурс буенча сайлап алынуны узган инициатив проектларны ачыклау критерийлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

17.5. Конкурс нәтиҗәләре буенча, йомгаклау бәяләвен исәпкә алып, критерияләр нигезендә комиссия инициатив проектларны конкурс сайлавын узган яисә узмаган дип игълан итү турында карарлар кабул итә.

17.6. Барлык критерийлар буенча максималь балл алган инициатив проект конкурста сайлауны узган дип игълан ителә.

## 18. Инициатив проектны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары

18.1. Инициатив проектны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе карар чыгара.

18.2. Инициатив проектны гамәлгә ашыру турындагы карарда түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) инициатив проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә төзелергә тиешле объект исеме (аның адресын яисә урнашу урынын күрсәтеп) яисә инициатив проект юнәлтелгән чара исеме;

2) муниципаль берәмлек бюджеты акчаларын тоту юнәлеше (төзелеш, реконструкцияләү, сатып алу, чара (чаралар) үткәрү, башкасы);

3) инициатив проектны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган муниципаль берәмлек бюджеты акчаларының баш бүлүчесе исеме;

4) заказ бирүче, төзүче исеме;

5) объектны файдалануга тапшыру (сатып алу), чараны (чараларны) гамәлгә ашыру вакыты;

6) инициатив түләүләр күләмен күрсәтеп, объектның фаразланган (чик) бәясе яисә чараны (чараларны) уздыруга акчаның иң чик күләме;

7) инициатив түләүләр күләмен күрсәтеп, объектның фаразланган (чик) бәясен яисә чараны (чараларны) уздыруга акчаларның иң чик күләмен еллар буенча бүлү.

## 19. Инициатив проект турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм урнаштыру тәртибе

19.1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының инициатив проектны карау турында, инициатив проектны гамәлгә ашыруның барышы турында, шул исәптән акчаларны тот турында, аны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның мөлкәти һәм (яисә) хезмәти катнашуы турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Балтач муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

19.2. Инициатив проектны гамәлгә ашыру йомгаклары турында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты хисабы инициатив проектны гамәлгә ашыру тәмамланган көннән алып 30 календарь көн эчендә “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Балтач муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

[1] Комиссия төзү конкурс нигезендә сайлап алуны уздырган очракта гына мәҗбүри булып тора.

Инициатив проектларны тәкъдим итү, карауга кертү, алар буенча фикер алышу һәм карау Тәртибенә
КУШЫМТА

## Инициатив проектларны конкурс нигезендә сайлап алу критерияләре, аларның күрсәткечләре, аларга туры килә торган баллар һәм әһәмиятле коэффициентлары

| № т/б | Конкурс нигезендә сайлап алу критериясе исеме | Конкурс нигезендә сайлап алу критериясе күрсәткече | Баллар саны | Әһәмиятле коэффициент |
|---|---|---|---|---|
| 1. | *(критерийлар төркеменең исеме күрсәтелә)* | | | |
| 1.1. | *(критерий исеме күрсәтелә)* | *(критерийның күрсәткече күрсәтелә)* | *(тиешле критерий дәрәҗәсенә ирешкәндә бирелә торган баллар саны күрсәтелә)* | *критерий әһәмиятенә бәйле рәвештә бер өлешләрендә әһәмиятле коэффициенты күрсәтелә, барлык әһәмиятле коэфффициентларының суммасы берне тәшкил итәргә тиеш)* |
| | | *(критерийның күрсәткече күрсәтелә)* | 90 балл | |
| | | *(критерийның күрсәткече күрсәтелә)* | 80 балл | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |